РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№4/5**

2021 елга Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлеге милкендәге мөлкәтне
хосусыйлаштыруның Фаразлау
планы (программасы) турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планын (программасын) расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы) 2021 елга Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru), шулай ук торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (torgi.gov.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Советының бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

Чистай шәһәр Советының
2020 елның «15» декабрендәге
4/5 номерлы карарына
Кушымта

**2021 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фаразлау планы (программасы)**

## 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) 2021 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. 2021 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль мөлкәтне сатудан бюджет кытлыгын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру аукционда яисә конкурста сату юлы белән һәм законда каралган башка ысуллар белән башкару күздә тотыла.

## 2 нче бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2021 елда муниципаль казнадагы һәм шәһәр бюджетыннан финанслanучы оешмалардан файдаланудагы муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштыруга планлаштырылучы муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге:

| № п/п | Объект исеме | Урнашу урыны | Мәйданы кв. м. | | Хосусыйлаштыруның күздә тотыла торган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Объект | Җир кишәрлеге | |
| 1 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, К.Маркс ур., 23 нче йорт | 98,2 | | 1-2 кв. |
| 2 | Торак булмаган бина, психологик-педагогик үзәк | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Галактионов ур., 42 нче йорт | 306,2 | 1 779 | 1-2 кв. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Торак булмаган бина, административ | Татарстан Республикасы, г.Чистополь, Тынычлык ур., 48 нче йорт | 771,4 | | 2-3 кв. |
| 4 | Торак булмаган бина | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Ак.Королев ур., 9А йорт, Н1 бинасы | 42,5 | - | 2-3 кв. |
| 5 | Торак булмаган бина, циферблатларның фосфор өслек цехы | Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре, Энгельс ур., 129 Л йорт | 259,3 | 2889,5 | 3-4 кв. |

2.3. 2021 елда муниципаль милектәге муниципаль унитар предприятиеләрне һәм акцияләрне хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. Муниципаль мөлкәтне, шул исәптән сату мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы карар сатып алучы затка мондый мөлкәт биләгән һәм алардан файдалану өчен кирәкле җир кишәрлекләрен бирү белән бер үк вакытта гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы карар Чистай шәһәр Советы карарлары нигезендә Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

## 3 нче бүлек. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

3.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү турында оператив мәгълүмат бирү максатларында Чистай шәһәр Башкарма комитеты әлеге фараз планын үтәү барышында мәгълүматның рәсми чыганакларыннан тыш башка массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтләреннән файдаланырга хокуклы.